СОВЕТ БОЛЬШЕПОЛЯНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЗУР ПОЛЯНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **с. Большие Полянки** **КАРАР**

**23.06.2026** **№ 22**

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 16.11.2018 ел, №82 карарына үзгәреш кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә туры китереп,

Зур Полянка авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Полянка авыл җирлеге Советының 16 .11.2018 ел, № 82 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) 2,5 % карата:

һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган салым салу объектларын, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш;»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Зур Полянка авыл җирлеге башлыгы, Совет Рәисе** **Р.Р. Гайнуллин**